**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.12.2021** **№ 977**

2022 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 февралендәге 273 номерлы Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2007 елның 11 декабрендәге 448 номерлы «Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга кушымтада китерелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнарны;

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына мәгариф оешмаларын финанслауны мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 нче пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р. Ф. Хисамутдинов

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесенең 2021 елның
03 декабрендәге 977 нче номерлы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карап тотуга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокациясе | Бер тәрбияләнүчегә, норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 98753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 148363 |